РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ГЛАВА
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
«УРМАНАЕВСКОЕ СЕЛЬСКОЕ
ПОСЕЛЕНИЕ» АЗНАКАЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЗНАКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
«УРМАНАЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ»
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШЛЫГЫ

ул. Татарстан д.15«а», с.Урманаево,
Азнакаевский район, 423311

Татарстан урамы, йорт 15 “а”, Урманай авылы
Азнакай районы, 423311

Тел./факс(8-85592)4-30-49/4-31-56; E-mail Azn.Urman@tatar.ru; http://aznakayevo.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

« 22 » ноябрь 2021ел № 05

2022 елда Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Урманай авыл җирлеге Урманай торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены үткәрү турында

2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьясы, 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Азнакай муниципаль районы Урманай авыл җирлеге Уставынын 15.1 статьясы нигезендә, карар итәм:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Урманай авыл җирлегенең Урманай торак пунктында Урманай авылы Татарстан урамы буенча 1-34 нче йортларда теркәлгән, сайлау хокукына ия гражданнар өчен 2022 елда үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының беренче этабын 2021 елның 04 декабрендә 9 сәгать 00 минутка билгеләргә.

2. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Урманай авыл җирлегенең Урманай торак пунктында, Г. Галиев урамы буенча 1-57 йортларда теркәлгән сайлау хокукына ия гражданнар өчен 2022 елда үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының беренче этабын 2021 елның 04 декабрендә 10 сәгать 00 минутка билгеләргә.

3. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Урманай авыл җирлегенең Урманай торак пунктында Татарстан урамы буенча 35- 63 йортларда теркәлгән, сайлау хокукына ия гражданнар 2022 елда үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының беренче этабын 2021 елның 04 декабрендә 11 сәгать 00 минутка билгеләргә.

4. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Урманай авыл җирлегенең Урманай торак пунктында Г. Галиев урамы буенча 58-115 йортларда теркәлгән, сайлау хокукына ия гражданнар өчен 2022 елда үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының беренче этабын 2021 елның 04 декабрендә 12 сәгать 00 минутка билгеләргә.

5. Билгеләргә:

- Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Урманай авыл җирлегенең Урманай торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенын оештыручы – Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Урманай авыл җирлеге башкарма комитеты;

6. Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорауны расларга:

«Сез, 2022 елда Урманай авыл җирлеге Урманай торак пункты территориясендә Беренче Төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы

ветераннарыннан һәм катнашучылардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, көндезге уку формасында укучы студентлардан тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 300 сум күләмендә үзара салым кертү һәм бу акчаларның җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- Бәйрәм чараларын оештыру һәм үткәрү (бүләк һәм сувенир продукция сатып алу, «Яңа ел», «Җиңү көне», «Сабантуй», «Халыкара өлкәннәр көне " бәйрәм чараларын үткәрү хезмәтләре күрсәтү»);
- Урманай авылы территориясен төзекләндерүне оештыру (МТЗ-82.1 тракторы өчен кар эттергеч сатып алу; МТЗ-82.1 трактор өчен роторлы печән чапкыч сатып алу; трактор өчен ягулык-майлау материаллары һәм запас частьлар сатып алу; трактор йөртүчегә килешү буенча хезмәт күрсәтү өчен түләү);

**«РИЗА»** **«КАРШЫ».**

7. Әлеге карарны, кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә, Урманай авыл җирлеге мәгълүмати стендларында һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында (http://aznakaevo.tatarstan.ru), Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» (http://pravo.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

8. Әлеге карар халыкка җиткерелгән көннән үз көченә керә.

9. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз артымнан калдырам.

Башлык: А.И.Закиров